Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Иске-Рәҗәп авыл җирлегенең башкарма комитеты

КАРАР

22.09.2020 №23

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 07 маендагы 11нче номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Иске-Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 07 маендагы 11нче номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Иске-Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “Программа бурычлары” бүлекчәсенең җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашуга җәлеп итү».

1.2. 3нче бүлекнең унберенче абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы
Башкарма комитет җитәкчесе М.Ә.Нугаев